ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д.5, с. Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Узәк ур., 5 нче йорт, Ямбулат авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.12.2017г. с.Ямбулатово № 46

Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган урыннар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 54-ФЗ номерлы, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге Советы
КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннарны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
2. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән биналарны бирү тәртибен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н.Әхмәтҗанов

Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетының
08.12.2017 ел № 46 карарына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар

1. Крестниково авылы, Казан ур., 2 «А» йорты Ямбулат авыл мәдәният йорты янында

Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетының
08.12.2017 ел № 46 карарына
2 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган бүлмәләр исемлеге

| № т/б | Адресы | Баланс тотучы |
|---|---|---|
| 1 | Крестниково авылы, Казан ур., 2 «А» йорт - авыл Мәдәният йорты | Ямбулат авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 2 | Ямбулат авылы, Үзәк урам, 5 йорт - Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитеты | Ямбулат авыл җирлеге башкарма комитеты |

Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетының
08.12.2017 ел № 46 карарына
3 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә сайлаучылар белән очрашулар уздыру өчен урыннар бирү шартларын билгели.

2. Ямбулат авыл җирлегенең башкарма комитеты Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Ямбулат авыл җирлеге Советы депутатларының салаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген билгели

3. Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән биналар түләүсез нигездә бирелә.

4. Депутатлар бинаны бирү өчен, сайлаучылар белән очрашу уздыру өчен, оешма җитәкчесе, учреждение, балансында бина урнашкан предприятие адресына бина бирү турында гариза җибәрә.

5. Гаризада чараны уздыру датасы, вакыты, дәвамлылыгы, катнашучыларның якынча саны, заявканы бирү датасы, чараны уздыру өчен җаваплы күрсәткечләр, аның контактлы телефоны күрсәтелә.

6. Бүлмәне бүлеп бирү турында гариза гариза гариза биргән көннән алып өч көн эчендә оешма, учреждение, предприятие җитәкчесе тарафыннан карала.

7. Биналар эш көннәрендә бу эш процессына комачауламау шарты белән бирелә. Ял (бәйрәм) көннәрендә бина оешма, учреждение, предприятиеләр җитәкчеләре белән килештереп бирелә.